РАСЛАНГАН ___________

А. Ю. Зәкиева Балтач район башкарма комитетының мәгариф идарәсе җитәкчесе

Якташыбыз Эльвира Ибраһимова истәлегенә багышланган

***«Җаным һаман сезнең янда яши”*** дип исемләнгән

нәфис сүз осталары бәйгесенең нигезләмәсе

***1.Гомуми мәгълүмат:***

Авылдашыбыз Эльвира Ибраһимова - Балтач районы Таузар авылы кызы, танылган журналист, диктор. “Татарстан”, “Болгар”, Актаныш, Биектау FM радиостанцияләре дикторы, “Азан” һәм “Иман” радиолары аша ислам кыйммәтләрен халыкка таратучы, “Ярдәм” милли ислам хэйрия фондының алыштыргысыз хезмәткәре. Актанышлылар башлангычын хөрмәт итеп, күңелләргә үтеп керә торган сихри тавышлы, Балтач төбәгенең Таузар авылы кызы Эльвира Ибраһимованың якты истәлегенә Балтач район башкарма комитетының мәгариф идарәсе, Балтач муниципаль районының “Мәктәптән тыш эшләр үзәге” өстәмә белем муниципаль бюджет учреждениесе, Балтач муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе “Таузар башлангыч мәктәп-балалар бакчасы” ***“Җаным һаман сезнең янда яши”*** дип исемләнгән нәфис сүз бәйгесе игълан итә.

***2. Конкурсының максаты һәм бурычлары:***

-сәнгатьле сөйләмгә өйрәнүгә омтылыш булдыру;

-нәфис сүз осталарын барлау һәм аларга иҗади үсеш өчен шартлар тудыру;

-татар телен, әдәбиятын һәм мәдәниятен пропагандалау;

-Таузар илендә туып, кыска гына гомерендә халкы күңелендә җуелмас эз калдырып киткән якташыбыз-Эльвира Ибраһимова белән горурлану хисе тәрбияләү.

***3.Конкурсны оештыручылар:***

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе;

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының “Мәктәптән тыш эшләр үзәге» өстәмә белем муниципаль бюджет учреждениесе;

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе “Таузар башлангыч мәктәп-балалар бакчасы”

Татарстан Республикасы Балтач районы “Хезмәт” газетасы.

***4. Үткәрү шартлары һәм тәртибе***:

Конкурста катнашучылар:

1. Мәктәпкәчә яшьтәге балалар (әзерлек төркеме);
2. 1- 4 сыйныф укучылары;